ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

## «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 18 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) 2 өлештә:

1 пунктта:

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) планлаштырылучы структураның гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре;»;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләре;»;

«г» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) территорияне планлаштырып үстерү характеристикалары турындагы, шул исәптән территориядә төзелеш алып баруның тыгызлыгы һәм параметрлары (шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән чикләрдә) хакындагы, торак, җитештерү, иҗтимагый-эшлекле һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектларының һәм мондый объектларның эшләве өчен һәм гражданнарның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектларының, шул исәптән коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларына, транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү

программаларына, социаль инфраструктураны комплекслы үстерү программаларына кертелгән һәм планлаштырыла торган структура элементы чикләрендә территорияне үстерү өчен кирәкле булган объектларның характеристикалары турындагы нигезләмәне. Федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру зоналары өчен мондый нигезләмәгә күрсәтелгән объектларны урнаштыру өчен кирәкле булган төзелеш алып баруның тыгызлыгы һәм параметрлары турында белешмәләр, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы $12^7$ өлеше нигезендә территорияне планлаштыру проектын килештерү максатларында әлеге объектларны урнаштыру планлаштырыла торган территориаль зоналарга карата аларның сакланышын тәэмин итү, территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең фактлагы күрсәткечләрен һәм халыкның мондый объектлар территориясеннән файдалана алуының фактлагы күрсәткечләрен тәэмин итү буенча планлаштырыла торган чаралар хакында мәгълүмат кертелә;»;

түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) үз эченә торак, җитештерү, иҗтимагый-эшлекле һәм башка билгеләнештәге капиталь төзелеш объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү этапларын һәм мондый объектларның эшләве өчен һәм гражданнарның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектларын, шул исәптән коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларына, транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына, социаль инфраструктураны комплекслы үстерү программаларына кертелгән объектларны төзү, реконструкцияләү этапларын алган территорияне планлаштырып үстерү чиратлылыгы турындагы нигезләмәләрне.»;

б) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү материалларына түбәндәгеләр керә:

1) планлаштырыла торган структура элементлары чикләре чагылдырылган җирлек, шәһәр округы территорияләренең, муниципаль районның авылара территориясенең планлаштырылучы структура картасы (карта фрагменты);

2) эшләр башкаручы тарафыннан әзерләнә торган инженер эзләнүләре программасында каралган күләмдә инженер эзләнүләренең нәтиҗәләре, әгәр территорияне планлаштыру документларын әзерләү өчен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә мондый инженер эзләнүләре башкару таләп ителгән очракларда;

3) капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләүне нигезләү;

4) транспорт инфраструктурасы объектларының урнашу урынын чагылдыра торган һәм территориядә транспорт белән тәэмин ителешнең гамәлдәге һәм фараз ихтыяҗларын исәпкә ала торган транспорт (гомуми файдаланудагы транспортны да кертеп) һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру схемасы, шулай ук урамнар-юллар челтәрен оештыру схемасы;

5) мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре схемасы;

6) территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре схемасы;

7) региональ әһәмияттәге объектларның, җирле әһәмияттәге объектларның планлаштырыла торган параметрларының, урнашу урынының һәм билгеләнешенең шәһәр төзелешен проектлау нормативларына һәм шәһәр төзелеше регламентлары таләпләренә, шулай ук чикләрендә территорияне комплекслы һәм тотрыклы үстерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территориягә карата аның җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре белән билгеләнгән территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең рөхсәт ителә торган минималь күләменең исәп күрсәткечләренә һәм халыкның мондый объектлар территориясеннән файдалана алуының рөхсәт ителә торган максималь күләменең исәп күрсәткечләренә туры килүләрен нигезләү;

8) гамәлдәге капиталь төзелеш объектларының, шул исәптән линия объектларының, сүтелергә тиешле объектларның, төзелеп бетмәгән объектларның урнашу урынын, шулай ук гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына үтеп керү юлларын чагылдыра торган схема;

9) территорияне планлаштыру проекты нигезендә территориядә төзелеш алып баруның планлаштырыла торган чишелеш һәм (яисә) күләм-пространство чишелеше вариантлары (торак яисә иҗтимагый-эшлекле зоналарда урнашкан планлаштырылучы структура элементларына карата);

10) территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чаралары исемлеге;

11) әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары исемлеге;

12) территорияне планлаштырып үстерү чиратлылыгын нигезләү;

13) Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән таләпләр нигезендә әзерләнгән территорияне вертикаль планлаштыру, территорияне инженерлык әзерләве һәм инженерлык саклавы схемасы;

14) территорияне планлаштыру нигезләмәләрен дәлилләү өчен башка материаллар.»;

г) 5 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты түбәндәгеләр турында карар кабул итә:

1) территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, һәм урнаштыруы Татарстан Республикасы

чикләрендәге ике һәм аннан артыграк муниципаль берәмлекләр (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территорияләрендә планлаштырыла торган региональ әһәмияттәге объектларны һәм капиталь төзелешнең башка объектларын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру документларын раслау хакында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 2, $3^2$ һәм $4^1$ өлешләрендә күрсәтелгән очраклардан тыш;

2) төзелеше, реконструкцияләве тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган һәм урнаштыруы территорияләрендә региональ әһәмияттәге объектны төзү, реконструкцияләү планлаштырыла торган Россия Федерациясенең башка субъектлары белән килештереп, Татарстан Республикасы белән уртак чиге булган Россия Федерациясенең ике һәм аннан артыграк субъектлары территорияләрендә планлаштырыла торган региональ әһәмияттәге объект урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында һәм аларны раслау хакында;

3) территорияләрендә муниципаль районның, шәһәр округының җирле әһәмияттәге объектын төзү, реконструкцияләү планлаштырыла торган муниципаль районнар, шәһәр округлары җирле үзидарәсенең бер яисә берничә органы территорияне планлаштыру документларын килештерүдән баш тарткан очракта, составын һәм эш тәртибен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган килештерү комиссиясе тарафыннан фикер каршылыкларын карау нәтиҗәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы $4^2$ пункты нигезендә территорияне планлаштыру документларын раслау турында.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш) һәм 2 пунктында күрсәтелгән документларның әзерлеген тәэмин итүне Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы гамәлгә ашыра.

3. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган очраклардан тыш, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә йә күрсәтелгән органның ведомство буйсынуындагы дәүләт (бюджет яисә автоном) учреждениеләре тарафыннан йә ул дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән дәүләт контракты нигезендә җәлеп итә торган башка затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла. Территорияне планлаштыру документларын, шул исәптән региональ әһәмияттәге объектлар, җирле әһәмияттәге объектлар урнаштыруны күздә тота торганнарын әзерләүне үз акчалары исәбеннән физик яисә юридик затлар гамәлгә ашыра алалар.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә территорияне планлаштыру документларын әзерләү Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасына таянып гамәлгә ашырыла.

5. Региональ әһәмияттәге объектларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 14 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән өлкәләрдә урнаштыру күздә

тотыла торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, әгәр Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру документларында мондый объектларны Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 14 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән өлкәләрдә урнаштыру каралмаган булса, рөхсәт ителми.

6. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү территориаль планлаштыру документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш документлары (территорияне планлаштыруның линия объектлары урнаштыру күздә тотылган документларын әзерләүдән тыш) нигезендә, коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларына, транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына, социаль инфраструктураны комплекслы үстерү программаларына, шәһәр төзелешен проектлау нормативларына, техник регламентлар, кагыйдәләр җыелмасы таләпләренә туры китереп, инженерлык эзләнүләре материалларын һәм нәтиҗәләрен, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) бердәй дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен, ачыкланган мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен, территорияләрдән аерым шартларда файдалану зоналары чикләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

7. Урман фонды җирләренә карата әзерләнгән территорияне планлаштыру документлары расланганчыга кадәр алар урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән килештерелергә тиеш.

8. Урнаштыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларына җир кишәрлекләре алу рөхсәт ителә торган региональ әһәмияттәге объектлар урнаштыру күздә тотылган территорияне планлаштыру проекты расланганчыга кадәр ул дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре алу турында карар кабул итәргә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы белән килештерелергә тиеш. Территорияне планлаштыру проектын Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең күрсәтелгән органы белән килештерү предметы региональ әһәмияттәге объектлар урнаштыру планлаштырыла торган зоналарның әлеге территорияне планлаштыру проектында каралган чикләреннән гыйбарәт.

9. Әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән территорияне планлаштыру проекты дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре алу турында карар кабул итәргә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына кергән вакыттан алып утыз көн эчендә әлеге орган планлаштыруның мондый проектына карата ризасызлык белдермәсә, ул килештерелгән булып санала.

10. Региональ әһәмияттәге объектны яисә башка объектны җирлек, шәһәр округы чикләрендә урнаштыру максатларында әзерләнгән территорияне планлаштыру документлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланганчыга кадәр алар мондый җирлек башлыгы, мондый шәһәр округы башлыгы белән килештерелергә тиеш. Килештерү предметы күрсәтелгән объектларны планлаштырып урнаштыруның үз чикләрендә шундый объектлар урнаштыру каралган территориаль зоналар өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентларын (линия объектларыннын тыш) үтәү өлешендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә туры килүеннән, шулай ук территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең фактагы

күрсәткечләре һәм мондый объектларның халык өчен территориаль яктан уңайлы урнашуының факттагы күрсәткечләре сакланып калуны тәэмин итүдән гыйбарәт.

11. Территорияне планлаштыру буенча әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән документларны алган көннән алып утыз көн эчендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына җирлек башлыгы яки шәһәр округы башлыгы тарафыннан мондый документларны килештерү яисә килештерүдән баш тарту юллана. Мондый документларны килештерүдән баш тарту түбәндәге нигезләрдә рөхсәт ителә:

1) әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән объектларны планлаштырып урнаштыруның үз чикләрендә мондый объектларны урнаштыру планлаштырыла торган (линия объектларыннан тыш) территориаль зоналар өчен билгеләнгән шәһәр төзелеше регламентларына туры килмәве;

2) территориянең коммуналь, транспорт, социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин ителешенең факттагы күрсәткечләренең һәм (яисә) планлаштырылган объектларны урнаштырганда әлеге объектларның халык өчен территориаль яктан уңайлы урнашуының факттагы күрсәткечләренең кимүе.

12. Әлеге статьяның 10 өлешендә каралган территорияне планлаштыру документлары җирлек башлыгына яисә шәһәр округы башлыгына кергән вакыттан алып утыз көн узганнан соң җирлек башлыгы яисә шәһәр округы башлыгы тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына территорияне планлаштыру документларын килештерүдән әлеге статьяның 11 өлешендә каралган баш тарту җибәрелмәгән очракта территорияне планлаштыру документлары килештерелгән булып санала.

13. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясының $1^1$ өлешендәге 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән затлар тарафыннан әзерләнгән территорияне планлаштыру документлары тикшерү һәм килештерү өчен шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына тапшырыла. Мондый документларны раслау турында карар әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

14. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документлар кергән көннән алып утыз көн эчендә аларны әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча бу документларны раслау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрү турында яисә мондый документларны кире кагу һәм аларны эшләп бетерергә җибәрү хакында карар кабул итә.

15. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документларны, кирәк булган очракта, әлеге статьяның 6 өлешендә каралган таләпләргә туры килүләрен килештерү өчен, компетенцияләреннән чыгып, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына юллый.

16. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документлар кергән көннән алып егерме көн

эчендә үз компетенцияләре чикләрендә мондый документларны тикшерәләр һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча бу документларны килештерү турында яисә мондый документларны кире кагу хакында һәм аларны эшләп бетерергә җибәрү турында карар кабул итәләр һәм бу хакта шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына хәбәр итәләр.

17. Территорияне планлаштыру документлары Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына кергән вакыттан алып егерме көн эчендә бу документларга карата әлеге органнар тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына ризасызлык белдерелмәгән очракта, әлеге документлар килештерелгән булып санала.

18. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты территорияне планлаштыру документларын әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә, мондый документлар кергән көннән алып ундүрт көн эчендә раслый.

19. Территорияне планлаштыру документлары расланган көненнән алып җиде көн эчендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан үз территорияләренә карата шундый документлар әзерләнгән җирлек башлыгына, шәһәр округы башлыгына җибәрелә.

20. Җирле администрация башлыгы әлеге статьяның 19 өлешендә күрсәтелгән территорияне планлаштыру документларын муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны һәм мондый документлар турындагы мәгълүматны муниципаль берәмлекнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтына (муниципаль берәмлекнең рәсми сайты булганда) урнаштыруны тәэмин итә.

21. Территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләр кертү, мондый документларны законнарда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри бастырып чыгару турындагы таләпне үтәп, аның аерым өлешләрен раслау юлы белән рөхсәт ителә. Мондый очракта территорияне планлаштыру документлары расланган өлешләргә карата килештерелә.

22. Региональ әһәмияттәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2017 ел, 26 май
№ 32-ТРЗ